ҖИР ЭШЛӘРГӘ ТИЕШ
Рөстәм Миңнеханов авыл хуҗалыгы җирләреннән максатчан файдалануны контрольдә тотарга кушты
> 2

«ОМИКРОН»НЫ КӨТКӘНДӘ...
Коронавирус йоктыручылар саны кабат арта башлаган
> 2

ТАГЫН БЕР ҖИҢҮ!
«КАМАЗ-Мастер» «Дакар» раллиенда унтугызынчы тапкыр беренчелекне алды
> 4

ТАБИБ-ОСТЕОПАТ:
«Бөтен авыруларның сәбәбе – аркада»
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 5 (28778) | Шимбә | 15 гыйнвар | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

БӘБИЛӘР ҺӘМ ӘНИЛӘРГӘ
ДӘҮЛӘТ ЯРДӘМЕ АРТА

Яңалык

Пособие күчтеме әле? Артканмы-юкмы? Пособие рәвешендә дәүләт ярдәме алучылар тарафыннан бу көннәрдә иң еш бирелә торган сораулар бу. Ник дигәндә, 1 гыйнвардан күп кенә пособиеләрнең артачагы хәбәр ителгән иде. Быел кайсы төр пособие күпмегә артачак? Бүген әнә шул сорауларга ачыклык кертәбез.

Илдар Мөхәммәтҗанов

1,5 яшькә кадәр пособие

Казанның Кадыш бистәсендә яшәүче Алсу Закирова 1,5 яшькә кадәрге балаларга түләнә торган пособие ала. Берничә көн элек гыйнвар ае өчен акча күчкән.

– Узган елның апрелендә кызыбызга яшь ярым булды. Шуннан пособиегә документлар җыеп тапшырдым. Шөкер, уңай җавап килде. Шуннан бирле ай саен пособие алабыз. Әле кичә генә гыйнвар аеныкы күчте. Быел артачак дигәннәр иде, үзгәреш күрмәдем әле. Акчасын баланың үзенә тотабыз. Әллә ни зур сумма булмаса да, бер хезмәт хакыннан икенчесенә кадәр акчасын җиткереп яшәгән гаиләгә менә дигән ярдәм инде бу, – ди ике кыз әнисе.

1,5 яшькә кадәрге пособие күләме, быел 5,8 процентка артып, 7493 сумга җитәчәк. Россия Социаль иминиятләштерү фондының Татарстан буенча бүлекчәсеннән хәбәр итүләренчә, ул февраль аеннан гына түләнә башлаячак. Гыйнвар ае өчен исә бу төр пособие элеккеге күләмдә түләнә. Әлеге акча баланың әнисенә генә түгел, әтисенә яки аны тәрбияләгән башка туганына да түләнә ала. Әлеге төр пособиене алу өчен гариза бала туганнан соң ярты ел эчендә бирелергә тиеш. Гариза язганда айлык керемнәрне күрсәтүче белешмә дә тапшырырга кирәк. Рәсми рәвештә эшләүчеләр – аны эш урыныннан, эшсезләр социаль яклау бүлегеннән алырга тиеш. Шәхси эшмәкәрләр пособиене Социаль иминиятләштерү фонды аша рәсмиләштерә.

3 яшьтән 7 яшькә кадәр пособие

Билгеле булганча, әлеге пособие 2020 елдан гамәлдә. Ул айлык керемнәре гаиләдәге бер кешегә туры килгән яшәү минимумыннан азрак булган гаиләләргә түләнә. Баштарак ул төбәктә балалар өчен билгеләнгән яшәү минимумының яртысы (узган ел Татарстанда 4856 сум иде. – **Ред.**) күләмендә билгеләнә иде. 2021 елның апрелендә аны исәпләү кагыйдәләре үзгәртелде. Хәзер аның күләме, гаиләнең айлык керемено карап, 50 процентка гына түгел (быел – 5216 сум), ә төбәктәге балалар өчен каралган яшәү минимумының 75 процентына (7824 сум) һәм 100 процентына (10433 сум) кадәр җитәргә мөмкин. Әлеге пособиене алу өчен, «Дәүләт хезмәтләре» порталы аша яки күпфункцияле үзәккә барып, гариза язарга кирәк. Документларның күчермәсен тапшырасы юк. Аларны, шул исәптән гаиләнең айлык кереме турындагы мәгълүматны ведомствоара хезмәттәшлек юлы белән тикшерәчәкләр.

3 яшькә кадәр пособие

Быел бу төркемгә кергән балаларга 10756 сум түләнәчәк. Узган ел ул 9713 сум тәшкил иткән иде. Әлеге пособие айлык кереме ике яшәү минимумы күләменнән азрак булган гаиләләргә бирелә. Беренче бала өчен бу акча – бюджеттан, икенче балага ана капиталыннан түләнә. Шуңа күрә беренче балага тиешле пособиене алу өчен, социаль яклау бүлегенә яки күпфункцияле үзәккә барып, гариза язарга кирәк. Икенче баласына 3 яшькә кадәрге пособие алырга теләүчеләр Пенсия фондына мөрәҗәгать итәргә тиеш.

Ялгыз ата-аналарга пособие

Хәтерләсәгез, узган ел 8–17 яшьлек баласын ялгызы гына тәрбияләүче ата-аналарга да пособие түләнә башлады. Быел аның күләме 6200 сум тәшкил итәчәк. Ялгыз ата-ана дигәндә, гаиләдә әти яки әни кешенең берсе вафат булган, хәбәрсез югалган яки туу турында таныклыкта күрсәтелмәгән очраклар күздә тотыла. Аерылган һәм үзара килешү нигезендә баласына алимент алучы ата-ана бу акчага өмет итә алмый.

Ахыры 2 нче биттә >

Эшсезләргә яңа пособие түләнәчәк

Быелдан Татарстанда эшсезләргә бала туганда бер тапкыр бирелә торган пособие түләнә башлый. Күләме – 18886 сум. Россия Пенсия фондыннан хәбәр итүләренчә, әлеге пособие ата-ананың икесе дә эшсез булган гаиләләргә генә бирелә. «Эшләмәүче ата-анага яки аның опекунына, уллыкка яисә тәрбиягә бала алган ата-анага бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү каралган. Ул элек социаль яклау органнары тарафыннан бирелә иде. Бер тапкыр бирелә торган түләү күләме 18886 сум 32 тиен тәшкил итә. Ике һәм аннан күбрәк бала туганда ул һәр балага түләнә», – диелә хәбәрдә. Аны алу өчен, бала тугач, алты айдан да соңга калмыйча, Пенсия фондында гариза язарга кирәк.

Без – икенче

Татарстан «Цифрлы үрләр» бәйгесенә тәкъдим ителгән проектлар саны буенча икенче урынга чыккан. Россия вице-премьеры Дмитрий Чернышенко әйтүенчә, бәйге тормышның барлык өлкәләрен цифрлаштыруны үстерү максатында оештырылган. Сәламәтлек саклау, мәгариф, торак-коммуналь хуҗалык өлкәләре һәм башка юнәлешләр өчен кирәкле чишелешләр тәкъдим ителгән. Проектларның 80 процентын төбәкләр тапшырган.

Быел бәйгегә рекордлы санда – 800гә якын гариза алынган. 64е финалга чыккан. Чернышенко искәртеп үткәнчә, илдә Президент Владимир Путин кушуы буенча икътисад һәм социаль өлкәнең төп тармакларын цифрлаштыру стратегиясе кабул ителгән. Быел шуның бишесе буенча цифрлы федераль проектлар тормышка ашырыла башлаган.

Проектлар саны буенча алдынгылар өчлегенә, Татарстаннан тыш, Мәскәү (беренче урында), шулай ук Свердловск өлкәсе һәм Санкт-Петербург (икесе дә – өченче) кергән.

Эшмәкәрнең эше җиңеләя

Премьер-министр Михаил Мишустин озакламый Дәүләт Думасында зур булмаган предприятиеләр өчен салым салуның автоматлаштырылган гади системасы турында закон проектының икенче укылышта кабул ителәчәген белдерде. Пилот төбәкләр арасында Татарстан да бар. Бу хакта ТАСС хәбәр итә. Мишустин әйтүенчә, әлеге режим хисап тапшырмауны күздә тота. Салым хезмәте предприятиенең керемнәре турында мәгълүматларны башка чыганаклардан (алар арасында банклар да булачак) җыячак.

Премьер-министр яңалыкның эшмәкәрләргә ярдәм итәчәгенә ышаныч белдергән. Закон проекты узган елның 21 декабрендә беренче укылышта кабул ителгән. Экспериментта, Татарстаннан тыш, Мәскәү шәһәре, Мәскәү һәм Калуга өлкәләре катнаша. Яңа салым режимыннан хезмәткәрләре саны 5 кешегә кадәр һәм керемнәре елына 60 миллион сумга кадәр булган компанияләр файдалана алачак.

Җәмигъ мәчетенең урыны билгеле

Казанның яңа Җәмигъ мәчетен Казансу елгасы яры буенда – Казан Кремленә капма-каршы якта төзү нияте бар. Бу хакта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Мәскәүдә Гайдар форумы тәнәфесендә сөйләп үтте, дип яза ТАСС. «Мәчет төзү урыны якынча билгеле. Әмма әле безгә килештерү процедурасын узарга кирәк», – дигән Президент.

Җәмигъ мәчетенең тәүге нигез ташын салу Болгарда ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга бәйле чаралар планына кертелгән. Моңа кадәр республика җитәкчелеге мәчет проектына халыкара конкурс игълан ителүен белдергән иде. Бинаның 10 меңгә якын кеше сыйдырачагы күздә тотыла.



kzn.ru

Көн кадагында

Карлы юллар канга буялмасын

Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәгълүматларына карасаң, Россиядә гыйнвар башыннан 2 меңләп юл-транспорт һәлакәте теркәлгән. Иң аянычлысы: шуларда 230 кеше үлгән. 700ләп кешенең гомерен коткарып калганнар.

Татарстандагы саннар да куандырырлык түгел. Әйтик, 1–12 гыйнвар аралыгында республикада 89 юл-транспорт һәлакәте булган. Шуларда 21 кеше үлгән һәм 121 кеше төрле җәрәхәтләр алган. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, юл-транспорт һәлакәтләре саны – 6,3, ә зыян күрүчеләр саны 14,8 процентка кимегән.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе башлыгы урынбасары Александр Разумнов әйтүенчә, 2021 елда республика юлларындагы аварияләр санын киметә алганнар. Узган ел 3684 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән, аларда 312 кеше һәлак булган һәм 4542 кеше зыян күргән. Аварияләр саны – 333 очракка, үлүчеләр – 19, яраланучылар 356 кешегә кимегән.

Шулай да, һава торышы аз гына көйсезләнүгә, юлдагы фаҗигаләр турында хәбәрләр арта гына. Әйтик, бу атнаның пәнҗешәмбесендә Казан юлларында 237 авария булган, дип хәбәр итә башкаланың ЮХИДИ идарәсе «Телеграм» каналы.

Атна тәмамланганда Татарстанда үлемгә китергән юл фаҗигаләре дә булды. Әйтик, Әлмәт районында микроавтобус һәм җиңел машина бәрелешеп, 25 яшьлек ир-ат һәм 35 яшьлек хатын-кызның гомере өзелде. Моннан тыш, тагын биш кеше зыян күргән.

Җомга иртәсендә М7 трассасында «Чаллы – Казан» маршруты буенча хәрәкәт итүче автобус кар чистарта торган машинага килеп бәрелде. Шуның аркасында берничә пассажир һәм кар чистарта торган машина йөртүчесе төрле дәрәҗәдәге имгәнүләргә дучар булды.

Атна азагында һава торышының кинәт үзгәрәсен белгечләр алдан фаразлаган иде инде. 15 гыйнварда буран, кар көртләре һәм җилнең секундына 20 метрга кадәр җитүен әйтә синоптиклар. Якшәмбе дә кар явачак, аерым районнарда буран көтелә. Һава температурасы төнлә −11...−16, көндезге сәгатьләрдә −8...−13 градус булачак.

Һава шартлары үзгәргән вакытта юлдагыларга аеруча игътибарлы булу кирәк. Иң элек, автомобильләр арасында тиешле араны саклау мөһим. Бу кагыйдә һава торышы яхшы чакта да үтәлергә тиеш анысы. Тизлек режимына карата да игътибарлы булу сорала. Һава торышы көйсез шартларда, рульне нык тотам дип санасагыз да, куып йөрергә кирәкми. Вазгыятьне юлдагы башка машиналар бозарга мөмкин бит. Машинада кечкенә балаларны махсус утыргычларга утыртып йөрү таләп ителә. Куркынычсызлык каеше эләктерелгән, машинаның фаралары чиста булырга тиеш. Иминлек таләпләре җәяүлеләргә дә кагыла. Бердәм коткару хезмәте телефон номеры да истән чыкмасын (112).

Сүзгә-сүз

Марат ХӨСНУЛЛИН, Россия вице-премьеры:

Россиядә елына 120 миллион квадрат метр торак төзелсен һәм сатылсын өчен, халыкның кереме елына 2,5 процентка арту кирәк. Әгәр керем үсми икән, димәк, ихтыяҗ да булмаячак.

(Гайдар форумындагы чыгышыннан)

ТАТАРСТАНДА – ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЛӘРЕ

Узган ел Татарстанда республиканың «Дәүләт хезмәтләре» порталы аша 13698184 гариза тапшырылган. Хәзерге вакытта портал аша 139 төрдә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтелә. Шулардан 111е социаль яктан әһәмиятле санала.

ИҢ КҮП ТАПШЫРЫЛГАН ГАРИЗА ТӨРЛӘРЕ

Медицина белгеченә язылу	13153107
Балага айлык пособие билгеләү	65408
Балалар бакчасы өчен түләүгә компенсация алу	64970

Прививкасыз шифаханәгә кертмиләр

Татарстанда COVID-19 инфекциясеннән прививка ясатмаган 600 пенсионерга шифаханәләрдә ял итү өчен бушлай юллама бирелмәгән. Алар вакцинациядән катгый рәвештә баш тарткан. Социаль иминиятләштерү фондының төбәк бүлеге шундый мәгълүматлар китерде.

Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева бу хәлгә ачыклык кертеп үтте. Ул фонд хезмәткәрләренә өлкән яшьтәгеләр арасында прививка кадату зарурилыгы турында аңлату эше алып барырга киңәш итте. Вице-премьер шулай ук шифаханәләргә юллама алырга теләүчеләрнең коронавируска тизрәк бирешүчеләр төркеменә керүенә басым ясады.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Иң затлы капитал

Җәмәгатьчелек фикерен өйрәнүче үзәкләр инде берничә тапкыр белдергәнчә, бүгенге яшьләребезнең яртысыннан артыгы чит илгә китеп бару, шунда яшәү һәм эшләү турында хыяллана. Әлбәттә, хыял әле ул – китү, сине анда көтәләр, дигән сүз түгел, һәркем дә теләгенә ирешә алмый. Тик шулай да андый ашкынуның сәбәпләре нидә? Ят илләрдә яшь буынга нәрсә калган? Бәлки, бу – бары яшьлек авантюризмы яисә дөнья күрәсе килү теләге, бер романтика гынадыр. Ләкин, белгечләр искәртеп килгәнчә, саналганнарны романтикага гына сылтап калдырып булмый.

Төп сәбәп, гади итеп әйткәндә, яшьләргә кадернең биредә тиешле дәрәҗәдә булмавына барып тоташа кебек. Яшьләр шундый халык: алар иҗтимагый һәм икътисади вазгыятьне дә, киләчәккә перспективаларны да, кем әйтмешли, тиреләре белән, интуитив диярлек сизә. Биредәге шактый ярлы хезмәт базары да, сине күтәрергә, «кеше итәргә» ашыкмаган социаль лифтлар да алар өчен яңалык түгел. Яхшы түләнә торган урыннарны төрле башлыкларның газизләре, «үз кешеләр» биләгәнен дә алар күреп үсә. Барысын да белгән, күргән яшь-җилкенчәк, әлбәттә инде, үзе өчен нәтиҗәләр дә чыгармый калмый: сәләт, тиешле дәрәҗәдә әзерлекле, белемле булу да киләчәктә сиңа уңыш, үз урыныңны табу, син теләгән тормыш шартлары гарантияләми икән бит. Яши-яши толерантланган, вазгыять белән килешкән өлкәннәр белән чагыштырганда, яшь кавем гаделсезлеккә бик тә сизгер. «Урманга карау», читкә «качарга» тырышуларны, мәсьәләгә объектив якын килгәндә, шулайрак аңлатып була кебек.

Ә инде проблемага тагын да киңрәк карап, аны гомумиләштергәндә, без кеше капиталы дигән байлыкка, дөресрәге, ул ресурсның һаман да заманча югарылыкка күтәрелмәвенә, андый мөһим юнәлешкә игътибарның тиешле дәрәҗәдә булмавына, гомуми кадерсезлеккә килеп төртеләбез төсле. Социаль лифт дигәннәре дә – шул кеше капиталының бер өлеше, чагылышы бит инде.

Нәрсә соң ул кеше капиталы? Аны башкача билгеле бер илдәге эшкә яраклы халыкның сыйфаты, шуңа ирешү дияргә дә буладыр. Андый капитал ул – һәр кешедәге гыйлем, һөнәрилек, осталык. Ул – шулай ук яхшы сәламәтлек, лаеклы тормыш шартлары: яхшы торак, яхшы хезмәт хакы. Кеше үссен, теләкләрен тормышка ашырсын өчен барлык шартлар да тудырылган, эшли икән – илдә кеше капиталы инде бар дияргә мөмкин. Һәм инде, алда саналганнар барысы да үтәлгән хәлдә, кеше капиталы ул – югары хезмәт җитештерүчәнлеге, аны тәэмин итә алу мөмкинлеге. Ягъни башкача әйткәндә, теләсә нинди эшне сыйфатлы һәм күләмле итеп башкара алу сәләте. Завод эшчесеме син, вуз укытучысымы, җитәкчеме, табибмы – мөһим түгел. Син – сыйфатлы һәм заманча продукция бирүче, сыйфатлы итеп хезмәт күрсәтүче әзерлекле белгеч. Дилетантларның, төрле сәлкәү сөякләрнең, «кода-кодагый»ларның гомумән дә булмавы. Кеше капиталы белән бергә җәмгыятькә тигез мөмкинлекләр, гаделлек килә. Гаделсез туфракта ул ярала алмый.

Кеше капиталы, әлбәттә инде, юктан бар була, капылт кына туа алмый. Ул барлыкка килсен өчен, озак еллар буе эзлекле һәм планлы эш-гамәл, барыннан да бигрәк күләмле инвестицияләр һәм теләк кирәк. Тик андый проектның ахыры һәрдаим уңышлы була, түккән чыгымнар соңыннан уны белән кире кайта. Икътисади уңышка, яхшы тормыш сыйфатына ирешкән илләрнең барысы да андый юлны үткән, ул капиталны тудырган…

Кемнәрдер рәхәт яшәешне чимал – нефть, газ, руда сатып яшәүдә күрергә мөмкин. Андыйларны – җир мае рәхәтлеккә чыгарганнарны, мәсәлән, Фарсы култыгына сыенган гарәп дәүләтләре арасында очратырга була. Тик теләсә кайсы илнең икътисади куәте, байлыгы барыбер табигый ресурслар, Ходай бүләге булган файдалы казылмалар түгел, ә без әйткән кеше, кадрлар, заман белән бергә атлаучы белгечләр, аларга ихтирам һәм кадер. Уңышка ирешү, сыйфатлы тормыш итү өчен табигый ресурслар булу һич тә мәҗбүри түгел. Моңа мисал – Кояш чыгышы иле, дөньяның өченче икътисады булган Япония. Япон утрауларында файдалы казылмалар юк. Шулай булгач, теләгәндә дә аларга салынып булмый. Башны һәм кулларны эшләтәсе – дөньяда иң яхшы автомобильләр, иң ышанычлы электроника җитештерәсе кала. Монысы инде без телгә алган капиталсыз һич ерып чыгарлык эш түгел. Җиһанның икенче икътисады Кытайны да нефть белән газга бай дип әйтеп булмый. Күк асты иле сатып алган «кара алтын» үзе тапканга караганда 2,5 тапкыр күбрәк (200 млн тонна чыгарылса, 500 миллионы читтән кертелә). Кытайның икътисади егәрен, алар дөнья базарына чыгарып торган товар ассортиментының һуш китмәле дәрәҗәдә икәнен беләбез. Авторитар Кытайда да кеше капиталының мөһимлеген, ашланган җирнең генә аш бирүен яхшы аңлый башлаганнар, диясе килә.

Чимал, табигый ресурслар чыгарып, аларны сатып яшәр өчен, кем әйтмешли, артык акыл, без бүген сөйләгән капитал кирәкми. Шул ук нефтьнең теге яки бу дәүләткә бүләкме әллә җәзамы икәнен дә төгәл генә әйтү кыен. Әгәр дә аның ише байлыктан башың әйләнмичә, аны һәм аннан килгән акчаны дөрес файдаланып, акыл белән яшисең, башка тармакларны да үстерәсең икән, ул – бүләк. Башкача кыланганда, шул ук нефть белән газ, шактый мәкерле мал булып, дәүләтне, җитәкчеләрне, хәтта халыкны да күпмедер бозып, җиңел килгәнгә өйрәтеп, без әйткән кеше капиталын да дистәләрчә еллар буе яралгы хәлендә тотарга сәләтле. Чимал чыгару ул бөтен дөнья чират торып алырлык машина ясау түгел. Технологияләр, заманча җитештерү дип һич тә баш катырасы юк.

Россиядә инновацион технологияләр дистә елларга соңарып үзләштерелә. Без яшәгән ил кеше капиталын тудыруда шактый артта. Ул капитал кыйммәт тора, күп акча сорый. Чимал сатып баеган саран олигархик капитализмга башкалар күз өстендә каш итеп күргән андый капитал кирәк микән? Ихтимал, кирәкмидер. Чөнки аңлы, гыйлемле, булдыклы, актив халык ул акча капчыкларының кыланмышларына, алар биредә майтарганнарга тыныч кына карап, риза булып тормаска да мөмкин – бәласеннән башаяк. Тормышның бүгенге хуҗалары моны яхшы аңлый. Илдәге икътисади һәм сәяси һава торышын билгеләүче катлауга бераз пассив, артык укымышлы булмаган, таләпләр куймаган, «на» дисәң кузгала, «трр» диюгә туктый торган күндәм кавем булса яхшырак. Тик менә илгә, халыкка начар. Яшьләргә дә начар. Шуңа алар арасында эмиграцион кәефләр көчле дә.

ҖИР БИТ УЛ!

«Җиргә мондый мөнәсәбәттә булырга ярамый, безнең иң зур байлыгыбыз ул. Өләшеп тә караганнар… Дөрес файдаланылса, бер хәл. Авыл хуҗалыгы җирен башта сатып алалар, аннан башка категориягә күчереп куялар да сатып җибәрәләр. Авыл хуҗалыгы җирләре эшләргә тиеш». Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Росреестр һәм Кадастр палатасы Татарстан буенча идарәсенең коллегия утырышында районнарда җирләргә контроль җитмәү җәһәтеннән шулай диде.

tatarstan.ru

Утырышта идарәнең узган елдагы эшчәнлегенә йомгак ясалды һәм быелга бурычлары билгеләнде. Рөстәм Миңнеханов иң элек республика дәүләт хакимияте органнары һәм муниципалитетларның Росреестр белән электрон хезмәттәшлеген уңай бәяләде. Ул 2022 елның Татарстанда Цифрлаштыру елы буларак игълан ителүен, шуңа күрә электрон документлар өлешен арттыру эшен дәвам итәргә кирәклеген искә төшерде.

Президент әйтүенчә, узган елда Җир һәм күчемсез милек турында бердәм мәгълүмат ресурсын булдыру буенча эксперимент кысасында зур эш башкарылган. Экспериментта 4 төбәк – Краснодар, Пермь крайлары, Иркутск өлкәсе һәм Татарстанның (Әтнә, Яшел Үзән һәм Питрәч районнары) катнашуын искә төшерик.

– Проектны уңышлы төстә гамәлгә ашыру өчен Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына башка хакимият органнары, районнар, Росреестр һәм Кадастр палатасы белән берлектә ЕГРНга моңарчы булмаган мәгълүматлар кертү эшен көчәйтергә кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Татарстанның административ чиге, торак пунктлар чикләре турында мәгълүматларны Бердәм дәүләт реестрына кертүне төгәлләү зарури.

Моннан тыш авыл хуҗалыгы җирләреннән максатчан файдалануны контрольдә тоту, элеккечә үк, мөһим бурыч булып кала, диде Рөстәм Миңнеханов.

«Муниципаль җир контрольлеге буенча районнарга бурыч куярга кирәк. Җир бит ул! Мәсьәләне контрольгә алырга кирәк. Ит – баш, сыер – аяк анда. Җирне бакча кишәрлегенә әйләндереп куючылар да бар. Инде бөтен шәһәр читендәге җирләрне сатып, үзләренә якты киләчәк булдырмакчылар. Ни генә эшләмиләр?! Теркәлгән җирләр файдаланылмый икән, димәк, иң катгый чаралар күрергә кирәк, – диде Президент.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, территорияләрне үстерү комплекслы төстә хәл ителергә тиеш:

– Торак пунктны киңәйтергә кирәклеген аңлыйм, әмма без бөтен шәһәр читен Шанхайга әйләндерә алмыйбыз. Мондый мәсьәләләрнең барысы да архитектура ягыннан катгый төстә килештерелергә тиеш. Катгый төстә! Ә инде иң мөһиме – социаль инфраструктурасы ягыннан. Анда бит кешеләр яшәячәк. Җирне саттылар. Кеше анда нидер төзеде. Аңа медицина хезмәте күрсәтергә кирәк, мәктәпләр һәм бакчалар кирәк, ә болар юк. Җир – эш урыннары да бит әле ул. Кешеләр анда яши һәм эшли.

Күпфатирлы торак төзелешен дә аерым игътибар үзәгенә алу кирәк. Файдалануга тапшырылганнан соң бөтен бинаны мәҗбүри теркәү турында тәкъдимне хуплыйм, диде Рөстәм Миңнеханов. Татарстан Президенты билгеләп үткән тагын бер мәсьәлә – законга кешеләрнең үз милекләренә хокукларын рәсмиләштерүне гадиләштерү мөмкинлеге бирердәй үзгәрешләр кертелгән. Республика Хөкүмәтенә, Росреестр идарәсе һәм җирле үзидарә органнары белән берлектә, торак йортларга хокукларны рәсмиләштерүне гадиләштерү турында яңа федераль закон нигезендә эшләү өчен норматив документлар әзерләргә, гараж амнистиясе турындагы законны гамәлгә ашыруны оештырырга кирәк.

2021 елда барлыгы 1,3 миллионнан артыграк теркәү гамәле башкарылган. Бу – 2020 елдагыга караганда 37 процентка күбрәк. Шул ук вакытта теркәү гамәлләренең 80 проценты күчемсез милек белән алыш-бирешләрне, хокукларның күчүен, арест һәм чикләүләрне теркәүгә кагыла. Кадастр учетына куюга бәйле мөрәҗәгатьләр саны 2020 елдагы белән чагыштырганда 16 процентка арткан. Тулаем алганда, 2021 елда 18 меңнән артыграк өлешкә кереп төзү килешүе теркәлгән. Узган елда барлыгы 117748 ипотека килешүе теркәүгә алынган. Аларның яртысыннан артыгрвгы (60803) торак өлкәсенә туры килә. Моннан тыш 7700 ташламалы ипотека һәм 899 «авыл ипотекасы» теркәлгән.

Президент прокурорларны котлады

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Россия Прокуратура хезмәткәрләре көненә һәм Прокуратура оештырылуга 300 ел тулуга багышланган тантаналы чарада катнашты. Тантана «Казан Экспо» күргәзмәләр үзәгендә узды.

Рөстәм Миңнеханов һәр ел саен һөнәри бәйрәмнәрнең Прокуратура хезмәткәрләре көненнән башлануын искәртте. «Залда прокурорларның берьюлы берничә буыны: олпат ветераннар, тәҗрибәле профессионаллар янәшәсендә өметле яшь белгечләрне күрү күңелдә зур канәгатьлек хисләре уята. Мөгаен, Россия прокуратурасының бөтен тарихын күренмәс җепләр белән бәйләүче буыннар дәвамчанлыгының иң әйбәт күрсәткечедер бу», – диде Президент.

Республика башлыгы әйтүенчә, Татарстан прокуратурасы үзенең алдына куелган бурычларны һәрвакыт намус белән үтәп килде. «Узган елда да шулай булды. Сез меңнәрчә гади кешенең хокукларын торгызуга ирештегез, кискен социаль мәсьәләләрне хәл кылуга булыштыгыз, закон бозу очраклары буенча нәтиҗәле чаралар күрдегез. Асылда сезнең тырышлык белән гражданлык җәмгыятендә төрле мәнфәгатьләр арасындагы бик нәзберек балансны саклауга ирешелә», – диде Президент тантанада катнашучыларга.

БӘБИЛӘР ҺӘМ ӘНИЛӘРГӘ ДӘҮЛӘТ ЯРДӘМЕ АРТА

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Йөклелек буенча пособие

Әлеге түләү булачак әни кешегә йөклелекнең җиденче аенда ачылган «больничный» кәгазе нигезендә бирелә. Ул 140 көн дәвам итә. Йөклелек буенча пособие булачак әнинең соңгы ике елдагы уртача хезмәт хакы буенча исәпләнә. Быел йөклелек буенча пособиенең максималь күләме 360164 сум тәшкил итә. Эшләмәүче йөкле хатын-кызга минималь пособие түләнә. Быел аның күләмен элеккеге 58878 сумнан 63932 сумга кадәр арттырдылар. Россия Пенсия фондының Татарстан буенча идарәсеннән хәбәр итүләренчә, әлеге пособиене алу өчен, йөклелекне расларга кирәк. Моның өчен теркәлү урыны буенча урнашкан хатын-кызлар консультациясенә исәпкә басу тиеш. Йөклелек буенча пособие алу өчен гариза язасы юк. Ул «больничный» кәгазе нигезендә түләнә.

Матди хәле авыр булган йөкле хатыннарга өстәмә пособие түләү дә каралган. Моның өчен гаиләдә җан башына туры килгән айлык керемнең төбәктәге бер яшәү минимумы күләменнән азрак булуы шарт. Быел ул Татарстанда 10756 сум тәшкил итә. Бу акча хатын-кыз йөклелек буенча исәпкә баскан көннән башлап бала туганчыга кадәр түләнә. Булачак әнинең әлеге пособиегә мохтаҗмы-юкмы икәнлеген ачыклаганда, күчемсез милек, машиналар да исәпкә алына.

Ана капиталында үзгәрешләр

Быелдан башлап ана капиталы фаразланган инфляция күләме буенча түгел, гамәлдәгесе буенча индексацияләнәчәк. 1 февральдән беренче бала тугач бирелә торган ана капиталы – 524,5 мең сум (узган ел 483,8 мең сум иде), икенче балага исәпләнгәне 168,6 мең сум (2021 елда – 155,5 мең сум) тәшкил итәчәк. Моңа кадәр бер тапкыр да ана капиталы алмаган гаиләләр өчен аның күләме – 693,1 мең сум (узган ел 639,4 сум иде).

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүз уңаеннан

Сарай исәпкә алынмаячак

Татарстанда һәр ике сумның берсе балалы гаиләләргә ярдәм итү өчен тотыла. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова министрлыкның еллык коллегиясендә шулай дип белдерде. Аның сүзләренә караганда, республикада айлык кереме яшәү минимумыннан түбәнрәк булган гаиләләрнең 72 проценты балалы.

– Узган ел башка еллар белән чагыштырганда күпкә күбрәк күләмдә пособиеләр түләнде. Әйтик, 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балаларга пособие түләү өчен генә дә 5 миллиард сум акча сарыф ителде. Тулаем алганда, республикада һәр ике сумның берсе балалы гаиләләргә ярдәм итү өчен тотыла, – дип белдерде министр үз чыгышында.

Гомумән алганда, узган ел социаль ярдәм өлкәсенә барлыгы 22 миллиард сум акча сарыф ителгән. Бер ел эчендә республикада эшсезләр саны да кимегән. Узган ел Татарстанда 37 мең эшсез исәпләнгән булса, быел андыйлар саны 11 меңне тәшкил итә.

Эльмира Зарипова сүзләренә караганда, «Демография» илкүләм проекты кысасында бер ел дәвамында 6 мең кешене яңадан укытканнар. Биредә инвалидлык, лаеклы ялга чыгар вакыты җитү, эшсез калу аркасында эшкә урнаша алмый тилмергән кешеләр турында сүз бара. Әлеге проект кысасында алар яңа һөнәр үзләштереп, эшле булган.

Быел кайбер социаль программаларга күптән көтелгән үзгәрешләр дә кертеләчәк. «Бездә аз керемле саналган һәм сарай кебек күчемсез милке булган кешеләр бар. Элегрәк алар соңгылары аркасында үзләренә тиешле социаль ярдәм чараларын ала, социаль контракт төзи алмый тилмерә иде. Яңа кагыйдәләр нигезендә исә мәйданы 15 квадрат метрга кадәр булган яшелчә саклау урыннары, сарайлар күчемсез милек рәтенә кертелмәячәк», – диде Эльмира Зарипова.

ТОТСА «ОМИКРОН» ЯКАҢ…

COVID-19

Быел кычкырмас өчен, былтыр нишләргә кирәк иде? Белгечләр, вакцина ясатасы, ди. Вазгыятьнең тотрыклылыгы саклансын, иммунитетның чиргә каршы торучанлыгы артсын өчен кирәк бу. Ә бит ике ай дәвамында чир йоктыручылар саны кимегәннән соң, республикада коронавирус белән авыручылар тагын арта башлаган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Узган елдан ук авыручылар саны кимүен күзәтеп килдек. Әйтик, чирләүчеләр саны 8, 20, 40 процентка кадәр кимегән атналар булды. Үткән атнада бу кимү акрынайды һәм нибары 10 процентны тәшкил итте. Гыйнварның беренче көннәрендә чирләүчеләрнең 8 процентка артуын күзәтәбез. Бу көтелгән иде. 6 атналык кимүдән соң үсеш башланды, – диде Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина.

COVID-19 белән чирләүчеләрдән тыш, грипп белән авыручылар саны да шактый.

– 544 очрак теркәлде. Пандемиягә кадәр чор белән чагыштырганда, рекордлы сан бу. Саклану чараларын күрүегезне сорыйбыз, – дип кисәтте Любовь Авдонина.

Шушы ике мәгълүматтан чыгып та, гамәлдә булган чикләүләрне юк итү турында сүз алып барылмавын аңларга мөмкин инде. Любовь Авдонина да: «Эпидемиологик вазгыятьне катлауландырмас өчен, чикләүләр сакланачак», – диде. Бу – Татарстанның ресторатор һәм кунакханә хуҗаларының эш вакытына үзгәрешләр кертүгә бәйле мөрәҗәгатенә дә кагылачак. Шунысы куандырмый калмас: Роспотребнадзор тикшерүләрне арттырмаска өметләндерде. Хәер, анысы – ике яклы мәсьәлә. Авыру йоктыргач, штрафы да, башкасы да мөһим түгел инде.

Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков коронавируска каршы вакцина ясатуга бәйле вазгыять турында сөйләде. Төгәлрәк әйткәндә, аны 200 меңнән артык кешенең кабат вакцина ясатырга килмәве борчуга сала икән.

– Хәзерге вакытта ревакцинацияне 147240 кеше узган. Узган елның июлендә, ягъни 6 ай элек, коронавируска каршы прививканы 382697 кеше кадаткан. Алар кабат вакцина ясатырга тиеш. Тик 235457 кеше һаман да прививкасыз, – диде ул.

Министр урынбасарын 65 яшьтән өлкәнрәкләрнең хәле аеруча борчый. Аларның 571794е – вакцинаның беренче дозасын, 418524е исә икенчесен алган. Пенсия яшендәгеләрнең гомуми санының 67 һәм 46 проценты дигән сүз бу. Владимир Жаворонков әлегә кадәр вакцина ясатмаган өлкәннәрне уйланырга чакырды. «Чир йоктырган очракта да, вакцинасы булганнар аны җиңелрәк кичерәчәк», – дип искәртте ул.

Гомумән алганда, Татарстанда коронавируска каршы вакцина ясатучылар саны 2311783 кешене тәшкил итә. Бу – халык санының 75,9 проценты дигән сүз.

Балалар вакцинасына бәйле кызыксыну да кимеми. Узган елның ноябреннән бирле сөйләнелә торган вакцина республикада әлегә юк. Владимир Жаворонков сүзләренчә, кайтартылгач, аны ничек файдалану һәм эшне ничек оештыру турында фикер алышалар. Бәлки, вакцина ясату сәүдә үзәкләрендә узар дигән фараз да бар.

Хәзер «омикрон» сүзе дә халык теленнән төшми. Бар игътибар инфекция таралган чит илләргә төбәлгән. Роспотребнадзор белгече яңа штаммның үзенчәлекләрен атады.

– «Дельта» штаммына караганда, «омикрон» җиңелрәк уза. Аның да үзенчәлекләре бар. Иң элек, бу – таралу тизлеге. Әйтик, ябык урында ул 4 мәртәбә тизрәк тарала. Авыру билгеләренә килгәндә, температураның 38гә кадәр күтәрелүе, тамак, буыннар авыртуы, борын тыгылу. Әлегә Татарстанда «омикрон» йоктырган кеше юк. Шул ук вакытта «дельта»ның да юкка чыкмавын истә тотарга кирәк, – дип аңлатты Любовь Авдонина.

Владимир Жаворонков әйтүенчә, «омикрон» турында сөйләгәндә һәм чит ил белән чагыштырганда, анда вакцина ясатучыларның саны Россиядәгегә караганда күбрәк булуын исәпкә алу мөһим.

– «Омикрон»ның җиңелрәк узуы турында сөйлибез, чөнки чит илдә халыкның күпчелеге вакцина ясаткан. Ягъни авыруның җиңел үтүе штаммның аерым үзенчәлеге дә, эпидемиологик «калкан» барлыкка килү нәтиҗәсе дә булырга мөмкин, – дип аңлатты белгеч.

Россия Хөкүмәте QR-кодка бәйле закон проектын кичектерергә уйлаган. Бу хакта вице-премьер Татьяна Голикова хәбәр итте. Аның сүзләренә караганда, закон проекты беренче укылышта «дельта» штаммы таралуга каршы тору чарасы буларак әзерләнгән иде, ә хәзер бурычлар башка.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ КАРАРЫ

гражданин Т.Ә. Вәлиев шикаятенә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешенең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча

Казан шәһәре 2021 елның 21 декабре

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Ф.С. Мусин, Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешенең конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданин Т.Ә. Вәлиев шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган норматив хокукый нигезләмәнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Ф.Р. Волкова мәгълүматын, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең граждан законнары бүлеге баш киңәшчесе Э.А. Даутова, суд утырышына чакырылган вәкилләр – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты вәкиле – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе юридик бүлеге башлыгы Р.Н. Сафин һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесе вәкиле – «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесенең торак сәясәте бүлеге башлыгы Г.Р. Абдулманова аңлатмаларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

билгеләде:

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Т.Ә. Вәлиев «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук – 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) 8 статьясындагы 8 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Шикаять биргән вакытта аталган норматив хокукый нигезләмә граждан үтенечнамәсе буенча вәкаләтле орган билгеләнгән тәртиптә бирелгән номер, чиратлылык турында белешмә бирергә тиешлеген күз алдында тоткан.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче үзенең хатыны, кызы һәм аның балигъ булмаган өч баласы белән гомуми мәйданы 26,05 кв. м булган тулай торак бүлмәсендә теркәлгән. Аның аз керемле дип танылган гаиләсе торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак 2010 елның 19 февраленнән исәптә торган. Торак урыны алуга үз чиратын ачыклау максаты белән гражданин Т.Ә. Вәлиев Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясенә мөрәҗәгать иткән, алар аңа Казан шәһәренең Идел буе районы буенча чиратлылык турында мәгълүмат биргәннәр. Шуның белән, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, аны ялгыштырганнар, чөнки Россия Федерациясе торак законнары нигезләмәләре буенча социаль наем шартнамәсе буенча торак урыннары аз керемле гражданнарга муниципаль торак фондыннан чиратлылык тәртибендә, мондый гражданнарны исәпкә алу вакытыннан чыгып бирелә һәм шуңа күрә Казан шәһәре районнарындагы чиратлылык әһәмияткә ия түгел. Шуңа бәйле рәвештә гражданин Т.Ә. Вәлиев тиешле мәгълүматларның граждан исәпкә алынган район буенча түгел, ә Казан шәһәре буенча бердәм чиратлылыктан чыгып бирелергә тиеш булуын күрсәтә. Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, Казан шәһәренә карата дәгъва белдерелә торган нормада гражданга чиратлылык турында нинди мәгълүматлар бирелергә тиешлеге – шәһәр яки район буенча булуы ачык билгеләнергә тиеш. Моннан тыш, ул билгеләп үткәнчә, карала торган нигезләмә эчтәлегеннән гражданга номер, чиратлылык турында белешмәләр нинди тәртип нигезендә бирелергә тиешлеге аңлашылмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүче үзенең конституциячел хокуклары бозылган дип саный һәм Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешен Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 28 (беренче өлеш), 55 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре – иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау – Татарстан Республикасының бурычы; Татарстан Республикасы – сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; закон һәм суд каршында һәркем тигез; һәркем торакка хокуклы; беркем дә торагыннан нигезсез рәвештә мәхрүм ителә алмый; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар.

Эшне суд утырышында карый башлаганда «“Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында” Татарстан Республикасы Законына һәм “Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 22 июнендәге 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән шикаять белдерелә торган нигезләмәгә бирелгән номер, чиратлылык турында граждан үтенечнамәсе буенча белешмәләр бирү тәртибе вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнүен төгәлләштерүче үзгәреш кертелгән. Шуның белән бергә, бу Татарстан Республикасы Конституция судына 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешен гамәлдәге редакциясендә карауга комачауламый, чөнки тулаем алганда аның хокукый эчтәлеге һәм хокук куллану практикасында мәгънәсе үзгәрешләр кичермәгән.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану гамәлиятендәге мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, әлеге эш буенча «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлеше муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алынган гражданнарга үзләренең чиратлары турында белешмәләр алу хокукын гамәлгә ашыру өчен хокукый нигез булып торган дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора.

2. Нигезләмәсенә карата гражданин Т.Ә. Вәлиев тарафыннан шикаять белдерелә торган «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын кабул итү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә кагылышлы мәсьәлә әлегрәк Татарстан Республикасы Конституция судының тикшерү предметы булган иде, ул, күрсәтелгән норматив хокукый актны кабул итеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының социаль яклау һәм торак законнары өлкәсендә Россия Федерациясе Конституциясендә билгеләнгән эшләр бүлешүдән чыгып эш иткән һәм федераль законнар һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә үзенә бирелгән вәкаләтен дөрес гамәлгә ашырган дигән нәтиҗәгә килде (2013 елның 18 октябрендәге 55-П номерлы, 2020 елның 16 июнендәге 91-П номерлы карарлар). Татарстан Республикасы Конституция судының күрсәтелгән карарлары һәм аларда чагылдырылган хокукый позицияләр үз көчләрен саклый.

3. Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасын сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), һәркемнең торакка хокукын беркетә; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар (55 статья). Мәгънәсе буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясендә, шул исәптән аның 7 һәм 40 (1 һәм 2 өлешләр) статьяларында билгеләнгән.

Әлеге конституциячел нормалар 1948 елның 10 декабрендәге Кеше хокуклары гомум декларациясенең 25 статьясы һәм 1966 елның 16 декабрендәге Икътисадый, социаль һәм мәдәни хокуклар турында халыкара пактның 11 статьясы нигезләмәләренә тәңгәл килә, алар, лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокук элементы буларак, һәркемнең торакка хокукын танылар.

Россия Федерациясе Торак кодексының 2 статьясы нигезендә дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары гражданнарның торакка хокукларын гамәлгә ашыру өчен үз вәкаләтләре чикләрендә шартлар тәэмин итәләр, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль торак фондыннан социаль яллау шартнамәләре яки торак урыннарны яллау шартнамәләре буенча гражданнарга билгеләнгән тәртиптә торак урыннар бирәләр (3 пункт).

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча үз вәкаләтләре чикләрендә карарлар кабул итеп, шактый дискрециягә ия, әмма ул тигезлек, гаделлек һәм ярашканлык конституциячел принциплары белән, хокукый җайга салуның билгелелек таләпләре белән, шул исәптән ул тудыра торган хокукый нәтиҗәләрдә дә чикләнгән.

Гражданин Т.Ә. Вәлиев тарафыннан шикаять белдерелә торган 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлеше нигезендә социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урыны бирүгә аның чираты турында граждан үтенечнамәсе буенча вәкаләтле органның үзе билгеләгән тәртиптә белешмә бирү бурычы беркетелгән.

Әлеге нигезләмә гамәлдәге хокукый җайга салу системасында үзенең норматив-хокукый эчтәлеге буенча социаль наем шартнамәсе буенча торак урыннары алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру механизмының бер өлеше булып тора, аның хокукый нигезен Россия Федерациясе Торак кодексының кителгән конституциячел күрсәтмәләре һәм нормалары тәшкил итә. Аерым алганда, әлеге Кодексның 49, 51, 52 статьялары нигезләмәләре буенча аталган механизм социаль наем шартнамәсе буенча җирле үзидарә органы тарафыннан аз керемлеләр һәм торак урыннарына мохтаҗ дип танылган гражданнарга муниципаль торак фондыннан торак урыны бирүне күздә тота, шулай ук торак урыннары бирү максатларында яшәү урыны буенча җирле үзидарә органы тарафыннан аларны исәпкә алу процедурасын үз эченә ала. Шул ук вакытта Россия Федерациясе Торак кодексының 49 һәм 57 статьялары нигезендә күрсәтелгән торак урыннары гражданнарга муниципаль торак фондыннан чиратлылык тәртибендә аларны җирле үзидарә органнарында исәпкә алу вакытыннан чыгып бирелә. Әлеге Кодексның 14 һәм 19 статьялары нигезендә, муниципаль берәмлекләргә милек хокукындагы торак урыннар бергәлеге буларак, мондый торак фондына карата булу функцияләрен җирле үзидарә органнары гамәлгә ашыра.

Шулай итеп, югарыда аталган норматив хокукый күрсәтмәләрнең эчтәлегеннән күренгәнчә, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыннары алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру механизмын тәэмин итү нигезендә чиратлылыкны саклау принцибы ята.

Китерелгән федераль нормалар нигезендә республика закон чыгаручысы үзенә бирелгән дискрецион вәкаләтләр кысаларында 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан аларга торак урыннары бирү тәртибен, шулай ук социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның исәбен алып бару тәртибен регламентлаган. Күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 8 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләреннән чыгып, гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу алар тарафыннан яшәү урыны буенча җирле үзидарәнең вәкаләтле органына тапшырылган гражданнар гаризалары нигезендә гамәлгә ашырыла, әлеге орган, үз чиратында, гражданнарны тиешле исәпкә алу (исәпкә алудан баш тарту) турында карар кабул итә. Карала торган Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 5 статьясы белән үзара бәйләнештә Казан шәһәре Башкарма комитеты вәкаләтле орган булып тора, аның структурасына территориаль органнар, аерым алганда, Казан шәһәренең Авиатөзелеш һәм Яңа Савин, Вахитов һәм Идел буе, Киров һәм Мәскәү, Совет районнары администрацияләре керә.

Шикаять белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 6 өлеше нигезендә торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алынган һәр гражданга вәкаләтле орган тарафыннан кирәкле документлар кертелгән исәпкә алу эше ачыла. Шул ук вакытта мондый гражданнар тарафыннан социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урыны алу чиратлылыгы алар тарафыннан гариза бирү вакыты буенча билгеләнә.

Карала торган Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезләмәләрен үстереп, «“Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында” 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларның формаларын раслау хакында» 2008 елның 31 гыйнварындагы 57 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исәпкә алу эшен алып бару тәртибен (алга таба – Тәртип) расламаган. Тәртип нигезендә социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә алынган һәр гражданга аны исәпкә алу өчен нигез булырлык кирәкле документлар кертелгән исәпкә алу эше ачыла; вәкаләтле орган карары буенча исәпкә алу эше социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның исәбен алып бару өчен җаваплылык йөкләнгән вазыйфаи зат тарафыннан алып барыла; исәпкә алу эшенә Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу кенәгәсендәге номерга туры килә торган тиешле номер бирелә; исәпкә алу эшендәге документлар алыну даталары буенча хронологик тәртиптә урнаштырыла, астан өскә таба, номер куела һәм алынуы буенча исемлеккә кертелә бара.

Шулай итеп, вәкаләтле орган, закон нигезендә үзенә беркетелгән вәкаләтләр кысаларында, гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар дип тану, аларны тиешле исәпкә кую һәм, димәк, мондый гражданнарның чиратлылык исемлеген алып бару механизмы эшен тәэмин итәргә тиеш.

Тәртипнең китерелгән нигезләмәләре белән үзара бәйләнештә Татарстан Республикасы Законының шикаять белдерелә торган нормасын анализлау күрсәткәнчә, ул үзенең табигате һәм максатчан билгеләнеше буенча гражданның социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү хокукын гамәлгә ашыруның реаль ихтималлыгын аңа алдан күрергә мөмкинлек бирә торган – исәпкә алу вакытыннан чыгып, муниципаль берәмлектә торак урыннары бирүгә чиратлылыкның гомуми исемлегендә үзенең чираты буенча нинди урында торуы турында белешмәләр алу хокукын тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Карала торган хокукый җайга салудан аңлашылганча, вәкаләтле органга гражданнарга аларның чиратлылыгы турында белешмәләр бирү буенча беркетелгән бурыч вәкаләтле орган – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты һәм аның территориаль органнары тулаем муниципаль берәмлек буенча гражданнарның чиратлылыгы турында бердәм мәгълүматларга ия булырга тиешлеген күздә тота.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәге нәтиҗәгә килә: гамәлдәге хокукый җайга салу системасында муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру механизмының элементы булып торучы 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлеше үзенең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча граждан үтенечнамәсе буенча вәкаләтле органның чиратлылык турында үзе билгеләгән тәртиптә белешмә бирү бурычын күз алдында тота, алар, исәпкә алу вакытыннан чыгып, муниципаль берәмлектә торак урыннары бирүгә чиратлылыкның гомуми исемлегендә үзенең чираты буенча кайда булуы турында күрсәтелгән хокукны гамәлгә ашыруның реаль мөмкинлеген чагылдырыр иде.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган норма үзеннән-үзе хокук куллану практикасында аны әлеге закондагы җайга салу белән ярашмый торган башкача аңлату мөмкинлегенә юл куймый һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу – шәһәр эчендәге районнар администрацияләре тарафыннан, ә торак бүлеп бирү башкарма комитетлар тарафыннан гамәлгә ашырылган муниципаль берәмлекләрдә гражданга үзенең чиратлылыгы турында бары тик үзе исәпкә алынган район буенча гына белешмәләр бирелә дип куллануны кире кага.

Дәгъва белдерелә торган норманы башкача аңлау һәм куллану социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урыны алуга гражданнарның хокукларын тәэмин итүнең конституциячел әһәмиятле максатлары белән туры килмәслек һәм нигезсез булыр иде һәм аның чиратлылыгы турында граждан үтенечнамәсе буенча вәкаләтле органның белешмә бирү бурычы, һәм, димәк, аның торак урыны алуга хокукының кайчан гамәлгә ашырылачагын алдан күрү мөмкинлеген чынлыкта гамәлдә булган һәм нәтиҗәле итүгә түгел, ә декларатив һәм иллюзор характерда булуына китерер иде.

Шуның белән бергә Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә кирәк дип саный.

Эшне тыңлауга әзерләү чорында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетыннан алынган мәгълүматтан һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесе вәкилләренең аңлатмаларыннан күренгәнчә, 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешен үтәү йөзеннән расланган вәкаләтле орган тарафыннан граждан үтенечнамәсе буенча шул исәптән аның муниципаль торак фондыннан торак урыны бирү чиратлылыгы турында белешмәләр бирү тәртибе юк. Карала торган Законның 8 статьясындагы дәгъва белдерелә торган 8 өлешендә каралган вәкаләтле органның граждан үтенечнамәсе буенча үзе билгеләгән тәртиптә аның чиратлылыгы турында белешмәләрне бирергә тиешлеге гражданнарның торак шартларын яхшыртуга хокукын гамәлгә ашыру механизмының аерылгысыз элементы булу фактын исәпкә алып, мондый мәгълүмат бирү тәртибе ачык, төгәл, ике төрле аңларга урын калмаслык итеп бәян ителгән бердәм хокукый һәм процедура кагыйдәләренә нигезләнгән булырга тиеш.

Хокук куллану практикасында барлыкка килгән дәгъва белдерелә торган норманы интерпретацияләү вариантларын анализлау фактта вәкаләтле орган тарафыннан гражданга үзенең чиратлылыгы турында белешмә бирү бурычын үтәү процедурасына төрлечә якын килү мөмкинлеге турында сөйли. Бу гражданның, ахыр чиктә, бары тик үзе исәпкә алынган Казан шәһәре районы буенча чиратлылыгы турында гына мәгълүмат алуына китерә. Бәян ителгәннәр республика закон чыгаручысының хакыйкый ихтыярын үзгәртү һәм гражданнарның хокукларын бозу турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды карала торган нигезләмәне бертөрле куллану максатларында Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую тәртибен регламентлый торган муниципаль хокукый җайга салу граждан үтенечнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү чиратлылыгы турында Казан шәһәре районнары администрацияләре тарафыннан белешмәләр биргәндә кулланылырга тиешле норматив материалны төгәлләштерү өлешендә камилләштерүне таләп итә дип саный.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлеше нигезләмәсе, аның дәлилләренә карамастан, әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәдә аның социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урыны алу хокукын чикләми һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дигән нәтиҗә ясый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешен, әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 102-П

Татарстан Республикасы Конституция суды

КОТЛЫЙБЫЗ!

«ТАНЕКО» акционерлык җәмгыяте генераль директорының техник хезмәт күрсәтү һәм инжиниринг буенча урынбасары **Головин** Вадим Евгеньевичка, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Төзелеш проектларын гамәлгә ашыру идарәсе матди-техник тәэминат хезмәте заказлар белән эшләү төркеме әйдәүче инженеры **Зыятдинов** Марат Җәүдәт улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Төзелеш проектларын гамәлгә ашыру идарәсе проект менеджерлары хезмәте баш белгече (проект җитәкчесе) **Ильичев** Андрей Игоревичка, «Түбән Каманың «Центромонтаж-автоматика» предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте 1 номерлы монтажлау участогының икенчел чылбырлар буенча электромонтажчысы **Кашапов** Ирек Мәсәбих улына, «СтройМонтаж-Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте 1 номерлы монтажлау участогының кулдан һәм дугалы электр һәм газ белән эретеп ябыштыручысы **Леньков** Игорь Николаевичка, «НЭС Профэксперт» кече инновация предприятиесе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Түбән Кама шәһәрендәге аерымланган бүлекчәсе төзелешнең сыйфатына контроль хезмәте төзелешнең сыйфатына контроль буенча инженеры **Миркасыймов** Рамил Миргазиян улына, «ТАНЕКО» акционерлык җәмгыяте генераль директорының техник хезмәт күрсәтү һәм инжиниринг буенча урынбасары хезмәтенең техник тәэминат идарәсе баш энергетигы – баш энергетик бүлеге башлыгы **Опарин** Артем Евгеньевичка, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Төзелеш проектларын гамәлгә ашыру идарәсе матди-техник тәэминат хезмәте заказлар белән эшләү төркеме инженеры **Старостин** Константин Владимировичка, «ТАНЕКО» акционерлык җәмгыятенең нефть эшкәртү заводы баш инженеры **Сөләйманов** Илмир Ринат улына, «Энергосила-НК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте төзелеш-монтажлау участогының икенчел чылбырлар буенча электромонтажчысы **Тузеев** Роман Захаровичка, «Татинтек» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең комплекслы проектларны тормышка ашыру идарәсе монтажлау һәм приборларны көйләү үзәгенең эшләр җитәкчесе **Фаздалов** Фоат Нуриәхмәт улына, «ТАНЕКО» акционерлык җәмгыяте генераль директорының техник хезмәт күрсәтү һәм инжиниринг буенча урынбасары хезмәтенең техник тәэминат идарәсе башлыгы **Федин** Олег Николаевичка, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте Төзелеш проектларын гамәлгә ашыру идарәсенең сатып алуларны оештыру бүлеге инженеры **Федотова** Наталья Борисовнага, «ТАНЕКО» акционерлык җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары (эксплуатация буенча) – җәмгыятьнең нефть эшкәртү заводы директоры **Хисмәтуллин** Айдар Миңнерәүф улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте Төзелеш проектларын гамәлгә ашыру идарәсенең төзелешне оештыру хезмәте техник күзәтчелек бүлеге инженеры **Хисмәтуллин** Денис Наил улына, «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе артисты **Меркушин** Михаил Алексеевичка, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе башлыгы урынбасары – техник күзәтчелек һәм теркәү-имтихан уздыру эше бүлеге башлыгы, полиция полковнигы **Бикмөхәммәтов** Дамир Равил улына, «СУГЫШЧАН ТУГАНЛЫК» бөтенроссия ветераннар иҗтимагый оешмасының Татарстан республика бүлекчәсе советы рәисе **Стогниев** Иван Даниловичка, «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенең «Алабуга электр челтәрләре» филиалы юридик төркеме җитәкчесе – әйдәүче юрисконсульты **Галимов** Игорь Эдуард улына, Зәй муниципаль районы финанс-бюджет палатасының бюджет бүлеге баш белгече **Габдуллина** Гөлсинә Рәшит кызына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген координацияләү идарәсе башлыгы урынбасары **Низамиев** Марат Фәрит улына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм кулланучылар базары идарәсе башлыгы **Фәттерахманов** Ленар Рифат улына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы идарә аппаратының финанслау бүлеге башлыгы **Вәлитова** Альбина Әлфир кызына, «Фундамент Плюс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Шәйхетдинов** Илдар Әнәс улына, «Татавтодор» акционерлык җәмгыятенең Саба филиалы директоры **Гарипов** Марат Гарәфетдин улына, **«Динамо-Казан» хатын-кызлар волейбол клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы коллективына**, **«Зенит» волейбол клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы (Казан шәһәре) коллективына Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

***

Прокуратура органнарында күпьеллык намуслы хезмәтләре, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Казан шәһәре Авиатөзелеш районы прокуроры урынбасары **Гавриленко** Елена Николаевна, Татарстан Республикасы прокуратурасының гомуми һәм махсус эш башкару бүлеге башлыгы **Шәрәпов** Минәкъдәс Әхтәм улы; театр сәнгатен үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Хисмәтов** Әсхәт Әсәдулла улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Республикада экологик куркынычсызлыкны һәм әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры **Шадриков** Александр Валерьевич; прокуратура органнарында күпьеллык намуслы хезмәтләре, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Казан шәһәре Идел буе районы прокуроры урынбасары **Алешин** Алексей Юрьевич, Казан прокурорының махсус режим объектларында законнарның үтәлешенә күзәтчелек буенча урынбасары **Гаянов** Илнур Мөдәррис улы, Татарстан Республикасы прокуратурасы органнары ветераны **Жаров** Александр Владимирович, Татарстан Республикасы прокуратурасы җинаять эшләрен судта карау идарәсенең апелляция бүлеге башлыгы **Фәттахов** Айрат Дөфәк улы, Татарстан Республикасы Прокурорының пенсия тәэминаты буенча өлкән ярдәмчесе **Һадиуллина** Аида Флорид кызы, Татарстан Республикасы Прокурорының гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү һәм кабул итү буенча ярдәмчесе **Хлыбова** Раиса Ивановна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы прокуратурасы хокукый статистика, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау идарәсенең мәгълүмат технологияләре бүлеге башлыгы **Камалов** Ленар Наил улына **«Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«АК БАРС Консалтинг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте юридик идарәсе башлыгы **Андреянова** Наталия Викторовнага; Татарстан Республикасы прокуратурасы җинаять эшләрен судта карау идарәсенең җинаять эшен тикшерү процессының кассация өлешендә прокурорларның катнашуын тәэмин итү бүлеге өлкән прокуроры **Вахитов** Равил Ринат улына; Татарстан Республикасы прокуратурасы федераль законнарның үтәлешенә күзәтчелек идарәсе социаль өлкәдә законнарның үтәлешенә күзәтчелек бүлеге (3 номерлы) башлыгы **Галимов** Айрат Рәшит улына; Татарстан Республикасы прокуратурасы тикшерү, башлангыч тикшерү алып баруга һәм оператив-эзләү эшчәнлегенә күзәтчелек идарәсенең башлангыч тикшерү алып бару производствосы һәм оператив-эзләү эшчәнлегенә күзәтчелек бүлеге башлыгы **Мулланулов** Ленар Шәрхенур улына; Татарстан Республикасы прокуратурасы тикшерү, башлангыч тикшерү алып баруга һәм оператив-эзләү эшчәнлегенә күзәтчелек идарәсенең эчке эшләр органнарында тикшерү алып баруга күзәтчелек бүлеге башлыгы **Надыршин** Радмир Илдар улына, Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре прокуроры урынбасары **Сәлимуллин** Айдар Мөнир улына, Татарстан Республикасы прокуратурасы федераль законнарның үтәлешенә күзәтчелек идарәсе башлыгы **Шараев** Марат Мәгъруф улына, Татарстан Республикасы прокуратурасының җинаять җәзаларын үтәтүнең законлылыгына күзәтчелек бүлеге башлыгы **Йосыпов** Айдар Ренат улына **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Спорт

kamazmaster.ru

19 нчы җиңү

Чаллының «КАМАЗ-Мастер» командасыннан Дмитрий Сотников экипажы «Дакар» раллиенда җиңү яулады. Ул узган елгы ярышта да беренче булган иде. Безнекеләрнең бер экипажы да көндәшләрне алга чыгармады. Бу – Татарстан командасының әлеге раллидагы 19 нчы уңышы.

Быел 44 нчесе оештырылган «Дакар» ярышына 2 гыйнварда старт бирелде. «Завод, шәһәр, республика һәм ил җитәкчелегенең, спорт сөючеләрнең бездән ни көткәнен беләбез. Аларны шатландыру өчен кулдан килгәннең барысын да эшләячәкбез», – диде команда җитәкчесе Владимир Чагин ралли башланыр алдыннан. Чаллы егетләре бу ярышка 4 экипаж белән чыкты. Аларның икесе автомобиль спорты белән якыннан кызыксынган кешегә яхшы таныш «КамАЗ-43509» булса, калган икесе – К5 төренә кергән «КамАЗ-435091» машиналары. Яңа автомобильләрне тәҗрибәле йөртүчеләр – узган ел җиңүче булган Дмитрий Сотников белән раллины 5 мәртәбә откан Эдуард Николаевка ышанып тапшырдылар. Калган ике экипажны исә Антон Шибалов белән Андрей Каргинов җитәкләде.

Ярышның беренче этабы Дмитрий Сотниковның җиңүе белән тәмамланды. Эдуард Николаев исә финишка икенче булып килде. Ә икесенең арасындагы вакыт – нибары 38 секунд! Төп узышның 3 сәгать 53 минут 14 секунд дәвам иткәнен исәпкә алсак, Согуд Гарәбстаны чүлләрендә көндәшлекнең ни дәрәҗәдә кискен булганын да чамалау кыен түгел. Чаллы командасының калган ике экипажы беренче этапны дүртенче һәм бишенче булып тәмамлады.

Икенче этап та «КАМАЗ-Мастер» егетләренең җиңүе белән тәмамланды. Алай гына да түгел, алар беренче дүрт урынны алды! Алга китеп булса да әйтик, быелгы автоузышта Чаллы спортчылары барлык этапларны да беренче булып тәмамлады. Безнекеләрнең тәҗрибәсе һәм осталыгы гаҗәпләндермәсә дә, Татарстан командасының зур өстенлеге кайбер көндәшләрне чыгырыннан чыгарды. Әйтик, 8 нче этаптан соң Голландия узышчысы Маурик ван дер Хевель шау-шу куптарды: «КАМАЗ-Мастер» командасы юлның кайдан үтәсен алдан ук белеп тора һәм шуның аркасында башкаларны уза. Аларның машиналарында махсус җиһаз урнаштырылган. Бу – гаделсезлек, аларны җиңеп булмый!» – дип сөрән салды ул. Тик серле мәгълүматны кем җиткерүен генә әйтмәде. Бәлки оештыручылардыр? Юк, әлбәттә! Оештыручыларга, киресенчә, «КАМАЗ-Мастер»ның җиңелүе һәм көндәшлекне кыздыру кирәк. Соңыннан Голландия спортчысының үз сүзләреннән баш тартканын хәбәр иттеләр. Артык кызып киткән икән.

Шул ук вакытта төрле командаларның юлда бер-берсенә ярдәм итү очраклары да юк түгел. Меңләгән чакрым озынлыктагы юлда иртәгә кем белән ни буласы билгеле түгел чөнки. Согуд Гарәбстаныннан килеп ирешкән видеоязмаларда «КамАЗ» машиналарының ком тавыннан сикереп, чокырларны сизми дә узганы сурәтләнсә дә, чынлыкта тишелеп ертылган көпчәкләр, ватылган тәрәзәләр күп булды. Узышчылар юлда туктап калмасын өчен, махсус команда төн буе аларны киләсе этапка әзерли. Монысы – ярыш машиналары белән гадәти «КамАЗ» арасында уртаклык табарга азапланучылар колагына. Аерма чыннан да җир белән күк арасы. Әмма машина белән безнең егетләр идарә итә.

Җомга алар Җиддәдә тәмамланган соңгы этапны да отты. Гомуми зачетта безнекеләр беренче өч урынны яулады. Дмитрий Сотников экипажы – беренче, Эдуард Николаевныкы – икенче, Антон Шибалов егетләре исә өченче булды. Хәтта дүртенче урын да Чаллы командасыннан Андрей Каргиновка насыйп булды. Бу – «КАМАЗ-Мастер»нең «Дакар»дагы 19 нчы уңышы.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «КАМАЗ-Мастер»ның «Дакар-2022» халыкара раллиенда җиңүе уңаеннан «КамАЗ» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры Сергей Когогинга, команда җитәкчесе Владимир Чагинга, «КАМАЗ-Мастер» командасына котлау юллады.
«КАМАЗ-Мастер» командасының «Дакар-2022» халыкара раллиенда җиңүе уңаеннан эчкерсез котлауларны кабул итегез, – диелә анда. – Искиткеч зур җиңү һәм бөтен команданың югары дәрәҗәдәге осталыгы, дөньяда тиңе булмаган Татарстан мустангларының өстенлеге дәлиле бу. Бөтен ил ике атна буе «Зәңгәр армада»ның, стартган алып финишка кадәр беренчелекне югалтмыйча, саллы көндәшләренә өмет чаткысы калдырмыйча, Гарәбстан чүленең буталчык юлларын зур осталык белән узуын, экстремаль автомарафонның барлык кыенлыкларын лаеклы төстә җиңүен сулыш та алмыйча күзәтеп торды. Республикабызга һәм бөтен Россиягә рәттән икенче тапкыр җиңү китергән Дмитрий Сотниковның каһарманнарга тиң экипажын аерым котлап үтәсем килә. Сезнең белән, күренекле якташларым белән чын күңелдән горурланам. Иң абруйлы ярыштагы күркәм көрәшегезгә рәхмәт белдерәм! Алга таба да «Алтын бәдәви»не кулдан ычкындырмавыгызны, уңышлар һәм яңа зур үрләр телим!»

ТАБИБ-ОСТЕОПАТ:

«БӨТЕН АВЫРУЛАРНЫҢ СӘБӘБЕ – АРКАДА»

Ютазы районына сәфәргә баргач, Урыссу бистәсендә күп авыруларга файдасы тигән, кулы шифалы табиб барлыгын әйттеләр. Аның үзен күреп, танышып чыгарга булдык. Татарстанның атказанган табибы, мануаль терапевт Ленар ХӘЛИУЛЛИН белән аның эш урынында очраштык. Вакыты тыгыз булса да, безнең белән сөйләшергә җай тапты.

Республиканың көнчыгыш районнарында яшәүчеләр өчен яхшы таныш, тәҗрибәле табиб 1979 елда Казан дәүләт медицина институтын тәмамлаган. Шуннан соң бер ел Лениногорск районының Шөгер авылында эшләгән дә туган авылы Бәйрәкәгә кайтып төпләнгән. Шушы авыл кызы белән гаилә корган. Авылда ук зур булмаса да, уңайлы, матур гына хастаханә салып, халыкка ярдәм иткәннәр.

Әйтергә кирәк, Ленар әфәнденең хатыны да, балалары да – табиблар. Авыл хастаханәсендә дә ирле-хатынлы эшләгәннәр. Хатыны – терапевт, үзе – хирург, уллары – стоматолог, кызлары – УЗИ ясаучы табибә. Ленар Хәлиуллинны, 15 ел буе авылда баш табиб, хирург булып эшләгәч, Урыссудагы хастаханәгә баш табиб итеп билгеләделәр. Ул эшләгән елларда биредә тагын бер хастаханә сафка бастырыла. 1991 елда медицинаның яңа юнәлеше – остеопатия, мануаль терапия белән кызыксына башлый. Инде менә соңгы ун елда бары тик шушы юнәлеш буенча гына эшли. Шуңа күрә дә сорауларыбыз әлеге юнәлешкә кагылышлы булды.

:: Ленар Әкрәмович, остеопатиянең төп нигезе нәрсәдә?

– Остеопат – авыруларны дару белән түгел, кул белән дәвалый торган табиб. Баш, муен, арка, кул авыртуларын, буыннарны дәвалый. Җәрәхәт алганнан соң да миңа киләләр. Соңгы елларда арка авыртулар ешайды. Авырулар монда килеп, шифа таба. Бу вакытта мин иң беренче эш итеп умыртка баганасына игътибар итәм, чөнки ул аз хәрәкәтләнә. Кешенең бөтен авыруы – аркасында. Остеопат кысылып торган урыннарны кузгатып җибәрә. Умырткалык ул – йөрәк шикелле үк үзе аерым орган. Аңа сөяк дип кенә карау дөрес түгел. Шуңа дөрес дәва гына таба белергә кирәк. Кешенең еллар буе баш, йөрәк авыртуының да сәбәбе әнә шунда булырга мөмкин.

:: Кеше үзен формада тотар өчен нинди күнекмәләр эшләргә тиеш?

– Дөрес итеп утырырга кирәк. Умырткалыкка иң күп көч утырган вакытта килә. Артык йомшакка утырырга ярамый. Күп кенә офисларда артлы кресолоарда утыралар. Бу – иң начар әйбер. Иң яхшысы – каты, артсыз урындыкка утыру. Утыру гына түгел, дөрес итеп йөрергә дә кирәк. Ашыгып, кабаланып, зур атлап йөрүгә караганда ипләп кенә, вак-вак атлап йөрү күпкә яхшырак. Яссы табанлы аяк киемнәре кию дә яхшы түгел. Аның бераз үкчәсе булырга тиеш, ләкин ул уңайлы булсын. Кулны кесәгә тыгып йөрү дә, өс киеменең капюшонын кию дә файдага түгел.

:: Соңгы елларда нинди авырулар аеруча артты?

– Умыртка баганасындагы дискларда бүсер (грыжа) бик күп. Элек өлкәннәр авыруы гына иде ул. Хәзер яшьләрдә күп очрый. Хәтта 6 яшьлек балаларда да бар, чөнки кальций җитешми, ул дөрес үзләштерелми. Ә ул күп вакыт ашауга бәйле. Кальций дөрес үзләштерелсен өчен балык мае эчәргә кирәк. Без кечкенә вакытта әниләр бер аш кашыгы балык мае каптыра иде. Менә шуның файдасы зур булган. Хәзер дә балаларга витаминнар эчерү модада, ләкин барыбер балык мае җитәрлек күләмдә бирелми. Хәрәкәтләнү дә аз. Моннан тыш, умыртка баганасы, дисклар өчен сикерү бик зыянлы. Ни өчен бу авыру зур йөк машиналарын йөртүчеләрдә еш очрый? Чөнки алар кабинадан сикереп төшә. Әти-әниләр урынында булсам, балаларын батуттан да сикерттермәс идем. Скакалка белән сикерүне дә файдалы дип әйтеп булмый. Умыртка баганасы әйберне дөрес итеп күтәрмәгәнлектән дә зыян күрергә мөмкин. Бигрәк тә капчык, тартма яки кешене күтәрергә туры килсә. Күтәргән очракта да тоткычы булган һәм авырлыгы 5 килограммнан артмаган сумкаларны гына күтәрергә кирәк. Авырулар килеп чыгуына дөрес итеп йокламау да йогынты ясый. Ян белән һәм аркада йоклау – иң дөресе. Йоклый торган урын катырак булса яхшы. Шулай ук арканы бик каты җылытырга да ярамый. Ниндидер мазьларны чамадан тыш күп сөртүнең, мунчада артык кыздыруның нәтиҗәсе еллар узгач килеп чыгарга мөмкин. Кайбер медицина оешмалары умыртка баганасын тарттырып дәвалый. Мин аны шулай ук хупламыйм.

:: Бала туганда алынган җәрәхәтләрне өлкән яшьтә дәвалап буламы?

– Була. Бары тик яхшы табибка гына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Без, табиблар, моңа кадәр булган авыруларның да елдан-ел катлаулануын күрәбез. Элек күпчелек авыруны дәвалар өчен бер сеанс җитә иде. Хәзер авыруны аякка бастырыр өчен 5–10 сеанс кирәк. Чөнки, беренчедән, кешеләр белгечкә авыру азгач кына мөрәҗәгать итә. Икенчедән, белмичә, үзлегеннән өйрәнеп дәвалаучылар саны артты. Шуңа күрә табибның лицензиясе бармы-юкмы – иң элек шуны сорагыз. Массаж ясатуга да сак карар идем. Теләсә кем массаж ясарга тиеш түгел.

:: Хиджама, сөлек салдыруга ничек карыйсыз?

– Мин аларга каршы түгел. Хиджаманы әниләр белән дәвалау дип тә әйтеп була. Аның төп үзенчәлеге кан чыгаруда түгел, ә энә белән сызуда. Сөлек шулай ук файдалы.

:: Күп авыруларның сәбәпчесе – эмоциональ блоклар, дип әйтәләр. Ул чыннан да шулаймы?

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Шулай. Безнең дәвалау нигезендә дә аларны таратып җибәрү, хәрәкәткә китерү ята. Бил авыртса, муен, күкрәк өлешенә дә зыян килә. Билне дәвалау гына уңай үзгәрешләргә китерми. Барысын да дәваларга кирәк.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ГӨЛИЯ ВӘЛИӘХМӘТОВА:

«РӘХМӘТ ӨЧЕН ЭШЛӘМИМ»

«Инстаграм»да утырып кына да ярдәмгә мохтаҗ балалар һәм өлкәннәргә булышучылар турында бер генә язмадык. Танылган композитор Марат Мухинның тормыш иптәше Гөлия Вәлиәхмәтова – шундыйлардан. Йөз меңнән артык кешеле аудиториясе белән ул башкаларның күңелен күрергә, тормышын җиңеләйтергә тырыша.

Мәктәпне тәмамлагач, Казанга укырга килә ул. КХТИда белем алгач, кабат Нурлатка кайтып китә һәм анда 5 ел эшли. Соңрак янә Казанга килә. Вакытын бушка уздырмаска тырыша. Чит илләргә чыгып, андагы тормышны күрә.

– Бай илләрне дә күрдем, фәкыйрь яшәгәннәрен дә. Тормышка шөкер итәр өчен анысы да кирәк. 42 илдә булырга туры килде. Кайда гына булсам да, үзебезнең Татарстан күңелгә якын икәнен аңлап кайттым. Әле минем күрәсе килгән илләрем күп. Теләкләрне чынга ашырырга язсын, – ди ул.

Гөлиядән шәхси тормышы хакында да сораштык. Күпләр белә: ул – композитор Марат Мухинның хатыны. Аңа кияүгә чыгу интернетта популяр иткән дә инде үзен.

– 30 яшем тулгач, гаиләле буласым килә башлады. Йөргән егетләрем дә бар иде. Кияүгә чыгуымны да сорадылар. Үз кешемне көтәргә насыйп булган, күрәсең. Марат белән танышу мине үзгәртте. 8 ай очрашып йөрдек тә никах укыттык. Ирем – мине, мин аны яратам. Кызыбыз Әмирә үсеп килә. Тагын ни кирәк соң? – ди Гөлия. – Марат белән яши башлагач, «Инстаграм»да язылучыларым бик күбәйде. Бер ел эчендә 100 меңнән арттылар. Алар белән бергәләп яхшылык эшлибез хәзер. Элек тә кибет буенда сатучылардан, кирәкме-түгелме, бакчасында үстергән яшелчәләрен, чәчәкләрен сатып ала идем. Әнә шулай итеп, өлкәннәрнең тормышын җиңеләйтәсем килде. Авыру балаларны аеруча кызганам. Ничек тә аларны сөендерәсем килә.

Гөлия соңгы арада Рамзан исемле балага ярдәм итәргә алынган. Сабый зур кимчелек белән туган. Рамзан башка яшьтәшләре кебек булсын өчен аңа 3 миллион 300 мең сумлык операция кирәк була. Гөлиянең язылучылары бу акчаны ике көн дигәндә җыя.

– Төрле кешеләр бар. Кемдер акча җыюны хуплап та бетерми. Кайберәүләр бик теләп булыша. Мин бит кешеләрдән зур сумма җибәрүләрен сорамыйм. Һәркем үз мөмкинлегеннән чыгып ярдәм итә. Кемдер – 50, кемдер 100, 300 сум җибәрә. Әнә шулай итеп, аздан күп җыела да инде, – ди Гөлия. – Рамзанга беренче операция булды инде. Шуның белән бетәр дигән идек. Әмма тагын бер операция кирәк. Анысы өчен 2 миллион 700 мең сум акча сорыйлар. Шул акчаны да җыярга тотындык.

Рамзанга булышкан арада Марсель Сәлахетдиновка да ярдәм оештыралар. Аңа 400 мең сум акча җыеп бирәләр. Шулай ук Зиннәт исемле кызга колак аппараты алу өчен ярдәм итәргә алыналар.

– Барысына да булышып бетереп булмый, әлбәттә. Бик күпләрне кире борырга да туры килә. Аеруча ДЦП диагнозлы бала үстерүче әниләр күп яза. Аларны да аңлыйм. Һаман саен тернәкләндерү курслары узарга кирәк. Тик арадан бик тә ярдәм кирәклесен сайларга тырышабыз, – ди ул.

Гөлиягә еш кына, хәйрия фонды ач инде, дип әйтәләр икән. Ул үзе моны кирәксенми. Интернет аша кешеләргә булышып торуым да җитә, ди.

– Бер эшемне дә кеше белсен, рәхмәт әйтсеннәр өчен башкармыйм. Күңел кушканны гына эшлим. Кемнедер сөендерә алу – минем өчен зур бәхет. Гади кешеләрне яратам, – ди ул. – Тормыштан тәм табып яшәргә кирәк. Мин исә үз юлымны таптым. Сабыйларның йөзендәге шат елмаю, өлкәннәрне сөендерә алуым көч бирә. Теләк булса, бар эшкә дә өлгерәсең. Гаиләмә дә рәхмәт. Интернеттагы язылучыларыма да рәхмәтлемен. Алар булмаса, без зур суммалар җыя да алмас идек. Яхшы эшнең җирдә ятмавын беләм мин. Шуңа күрә игелек эшләргә тырышсак иде. Авыруларны сөендергән һәр кешегә бәхет елмайсын!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7043 данә
Гомуми тираж – 18156 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 205

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+